Республика Татарстан
ЛЯКИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Школьная, д. 1,
с. Ляки, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

Татарстан Республикасы
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛӘКЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ

Мәктәп урамы, 1 йорт,
Ләке авылы, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел 07 нче ноябрь № 5

**Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегендә 2023 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Ләке авылында халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге башлыгы

КАРАР чыгарды:

1. 2022 елның 18 ноябрендә 14.00 сәгатькә Сарман муниципаль районы, Ләке авылы, Тау башы ур., 12 а йорт адресы буенча урнашкан Ләке мәдәният йорты бинасында 2023 елда Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, I төркем инвалидларыннан, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү турында һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә килешәсезме:

1) зират территориясен киртәләү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләрне түләү) Ләке торак пунктында;

2) Ләке авылында кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) ;

3) Ләке  авылындагы урам утлары объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

4) Ләке торак пунктында МТЗ-82 махсус техника өчен ягулык-майлау материаллары һәм запчастьләр сатып алу;

5) МТЗ 82.1 тракторы өчен чапкыч сатып алу;

6) Ләке авылында җәйге вакытта территорияне һәм юл буе полосаларын чабу (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

7) Ләке авыл җирлегендә Питрау бәйрәме уздыру өчен призлар, бүләкләр сатып алу;

8) Ләке авылында  өлкәннәр һәм инвалидлар көнен уздыру өчен бүләк пакетлары сатып алу.

"ӘЙЕ "                " КАРШЫ?»

3. Әлеге карарны Ләке авыл җирлегенең информацион стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://https://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 7 көн эчендә бастырырга.

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы                                        Шәрипова Л. И.